| Каралды: | Килешенде: | Расланды: |
|---|---|---|
| гуманитар МБ утырышында | укыту-тәрбия эшләре буенча директор | Мәктәп директоры ___________ |
| җитәкче____________ / Р.Р.Вәлиева/ | урынбасары __________/Л.М.Леонтьева/ | /Р.И.Солягина/ |
| Беркетмә № 1. 31.08. 2020ел. | 31.08. 2020 ел. | Боерык № 74-о от 31.08. 2020 ел |

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

“Нармонка урта гомуми белем мәктәбе”

Югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Вәлиева Рәмзия Рөстәм кызының 5б сыйныфы өчен 2020 – 2021 нче уку елына

туган (татар) әдәбиятыннан эш программасы

2020-2021 нче уку елы.

**Татар әдәбиятыннан эш программасы**
**35 сәгать**

Предмет: татар әдәбияты
Класс: 5
Укытучы: : Вәлиева Р.Р..
Сәгатьләр саны:
барлыгы – 35сәгать; атнага – 1 сәгать.

План буенча проект дәресләре : 4
Программа: "Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы " (1-11нче сыйныфлар . рус телендә сөйләшүче балалар өчен) авторлары (Р.З.Хәйдәрова,Р.Л.Малофеева. – .Казан. Татар китап нашрияты. 2014 ел)

Дәреслек:Ә.Р.Мотыйгуллина, Р.Г.Ханнанова, Л.К.Хисмәтова. Татар әдәбияты. Рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче 5 нче класс укучылар өчен ) 2 кисәктә. КАЗАН “Мәгариф – вакыт” нәшрияты, 2014

## Аңлатма язуы.

## Татар әдәбиятыннан эш программасы
## 5 нчы сыйныф
## (35 сәг

**Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды:**

1. “Мәгариф турында” РФ һәм РТ Законнары.

- Федеральный закон от 29.12.2012г. №273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации»,
- Федеральный государственный образовательный стандарт основного общего образования, утвержденный приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17.12.2010г. №1897»
- «Порядком организции и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам начальнего общего, основного обшего и среднего общего образования, утвержденным приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 30.08.2013г. № 1015»

2. Образовательная программа основного общего образования муниципального бюджетногообщеобразовательного учреждения в соответствии с ФГОС ООО МБОУ Нармонской СОШ (утверждена приказом № 70-о от 29.08.2015 г.; внесены изменения: приказ №79_о от 27 августа 2016 г.; приказ № 118_о от 23.10. 2017 г. )

3. Программа: “**Рустелендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа”** (төзүче-авторлары: Ф. Х. Җәүһәрова, Казан 2013) Примерная рабочая программа учебного предмета « Татарская литература» для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык как родной) . Авторы-составитель: Хасанова Ф.Ф. Одобрена решением федерального учебно-методического объединения по общему образованию (протокол от 16 мая 2017 г. № 2/17)

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы МБОУ “Нармонка урта гомуми белем мәктәбе”нең 2020-2021 нчы уку елына “Укыту планы” (Принято решением педсовета, протокол №8 от 27 августа 2020 года и утвержденного приказом № 73-о от 27.08.2020 г.)

5. Федераль дәреслекләр исемлеге (федеральный перечень учебников, рекомендуемых к использованию при реализации имеющих государственную аккредитацию образовательных программ начального общего, основного общего, среднего общего образования (Список учебников МБОУ Нармонской средней общеобразовательной школы Лаишевского муниципального района Республики Татарстан на 2018-2019 учебный год (Принято решением педсовета, протокол №8 от 27 августа 2020 года и утвержденного приказом № 73-о от 27.08.2020 г.)

**Рус мәктәпләрендә укучы рус телле балаларга татар теле укытуның төп максатлары:**

Билгеле булганча, укытуның максаты җәмгыять тарафыннан куелган социаль заказ белән билгеләнә. Татарстан Республикасының белем бирү системасына куйган төп бурычы - иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле һәм ике дәүләт һәм чит телләрдә дә иркен сөйләшеп аралашучы билингваль (полилингваль) шәхес тәрбияләү.

Рус телле балаларга татар теле укыту максаты киңкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

**1.Танып белү максатының эчтәлеге**

Татарстан Республикасында яшәүче һәрмилләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш,шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннәнфайдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” (И.Л.Бим) булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайлана.

Татар исемнәрен, Татарстанның табигатен, җирлеген, топонимикасын дөрес әйтә белергә өйрәтү, аларның семантикасы белән кызыксындыру, балалар фольклоры, татар халкы авыз иҗаты, әдәбият-сәнгать вәкилләре белән беренчел таныштыру - башлангыч этапта танып белү максатының төп эчтәлеген тәшкил итә.

**2. Үстерү максатының эчтәлеге**

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләүсәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында үстерү, тәрбия максатларын даими күзаллап эшләү - укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты (Л.С.Выготский).

Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дидуктив фикерләү;
- хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;
- аралаш белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатияхисләре);
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

Программага сайланган эчтәлек нигезендә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча да эш оештырганда бу максатлар беренче планга куела.

**3. Тәрбияви максатның эчтәлеге**

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы укытуның эчтәлеге һәм методлары белән бәйле. Шуңа күрә программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләрен исәпкә алына. Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән, аларны кызыксындырган мораль проблемаларны ү зэченә алган эчтәлек, беренчедән, укыту процессында тәрбияви функция башкарса, икенчедән, турыдан-туры коммуникатив мотивация туу белән бәйле.

Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатларны тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру шушы максатка буйсындырыла һәм сөйләшү-аралашуга алып чыгуга кулайрак булган әдәби әсәрләрнең авторлары тәкъдим ителә.

**4. Белем бирү максатының эчтәлеге:**

Укучыларның татар теле буенчалексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлыктөрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматиккатегорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул

вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.Укучының гомуми урта белем бирү мәктәбен тәмамлаганда сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча түбәндәге белемнәргә ия булуы күздә тотыла.

**Тыңлап аңлау**

Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;
тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;
сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү.
сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;
ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

**Диалогик сөйләм:**

Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына жавап бирү һәм сораулар куя белү;
дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм**

Җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;
тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;
укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;
үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә информация бирә белү.

**Уку**

Татар алфавитындагы хәрефләрне таный белү;
хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
тексттагы тыныш билгеләренә карата тиешле пауза һәм интонацияләрне үтәү,өтерләр янындагы сүзләрне тиңдәшлек, эндәшү интонацияләре белән уку;
укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү; укыганда сүзлекләр куллана белү.

***Эш программасының эчтәлеге.***

Укыту планында 5 нче сыйныфта татар әдәбиятынан атнага 1 сәгать вакыт бирелә. Укыту атнасы – 35.
Татар әдәбиятыннан эш программасы мәктәпнең укыту планына, “Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы”на (1-11 сыйныфлар)” (Р.З.Хәйдәрова Р.Л.Малафеева. 2014) , рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). (Казан, «Мәгариф- Вакыт » нәшрияты, 2014 ел) (Мутыйгуллина Ә.Р.Ханнанова Р.Г. Хисмәтова Л.К.) ;
төп гомуми белем бирү оешмалары өчен программалар – федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп, 35 сәгатькә төзелде.
.

## 5. Укыту предметының төп эчтәлеге.

| № | Бүлекләр, темалар | Эш программасы |
|---|---|---|
| | | әдәби уку |
| 1 | Борын-борын заманда | 5 сәг. |
| 2 | Әкият яздым......укыгыз | 3 сәг. |
| 3 | Хыял канатларында | 3сәг. |
| 4 | Белем баскычлары. | 3 сәг. |
| 5 | Балачак –хәтерләрдә мәңге калачак. | 3сәг. |
| 6. | Ватаным өчен | 3 сәг. |
| 7. | Кояшлы ил-бәхет иле | 3 сәг. |
| 8. | Кеше табигать баласы. | 3 сәг |
| 9. | Эш беткәч көләргә ярый | 3 сәг. |
| 10. | Проект дәресләре | 4 сәг. |
| 11 | Йомгаклау | 2 сәг. |
| | **Барлыгы** | **35** |

### Укыту-методик комплекты

**Дәреслек:**

| № | Автор | Исеме | Басылу елы | Нәшрият |
|---|---|---|---|---|
| | Мотыйгуллина Ә.Р.<br>Ханнанов р.Г.<br>Хисмәтова Л.К. | “Татар әдәбияты” рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен 2 кисәктә. | 2014 | Казан “Мәгариф-Вакыт”нәшрияты. |

**Укытучы өчен методик кулланмалар:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мотыйгуллина Ә.Р.<br>Ханнанов р.Г.<br>Хисмәтова Л.К.<br>Гыйзәтуллина Л.М. | “Татар әдәбияты” –методик әсбап. | 2014 | Казан “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты |
| 2 | | ”Фән һәм мәктәп”,”Мәгариф” журналлары | | |
| 3 | Р.З. Хәйдәрова. | “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту” – 5 нче класс Казан ”Татармультфильм” нәшрияты, 2014. | 2014 | ”Татармультфильм” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 4 | Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева, Л.Ә. Гыйниятуллина | Диск. “Күңелле татар теле”, “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту” | 2013 | “Татармультфильм”, |
| 5 | Р. З. Хәйдәрова, Н. Г. Галиева, Л. Ә. Гыйниятуллина | Диск “Татар телен өйрәнәбез”, “Рус телендә сөйләшүче баллаларга татар теле укыту” | 2012 | “Татармультфильм”, |
| 6 | | Диск “Габдулла Тукай”, Татарстан,М.Җәлил | | |
| 7 | А. Ш. Асадуллин, Р. А. Юсупов | А. Ш. Асадуллин, Р. А. Юсупов “Рус телле балаларга татар телен укыту методикасы нигезләре” | 2010 | Мәгариф |

**Укучы өчен кулланмалар:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мотыйгуллина Ә.Р.<br>Ханнанов р.Г.<br>Хисмәтова Л.К. | “ Татар әдәбияты ” мәктәпнең 5 нче сыйныф рус балалары өчен дәреслек. | 2014 | Казан “Мәгариф-Вакыт” НӘШРИЯТЫ. |
| 4 | Р. З. Хайдарова, Р. Л. Малафеева | .Р. З. Хайдарова, Р. Л. Малафеева. Татарский язык в таблицах. | | |

**Контроль-тикшерү материаллары:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мотыйгуллина Ә.Р.<br>Ханнанов р.Г.<br>Хисмәтова Л.К.<br>Гыйзәтуллина Л.М. | Татар әдәбияты –методик әсбап. (кушымта ) | 2014 | Казан “Мәгариф-Вакыт” НӘШРИЯТЫ. |

**Электрон кулланмалар:**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Диск “Заман”, “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту” | 2008 | Казан |
| 2 | Аудиодисклар “Җырлап-биеп уйныйбыз!” | 2008 | |

**Интернет ресурслар:**

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | http://www.tatmedia.com<br>http://www.tatar.ru<br>http://www.selet.biz/<br>http://www.tatar.com.ru | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | http://www.kltaphane.tatar.ryu<br>http://www.matbugat.ru<br>http://www.belem.ru<br>http://edu.tatar.ru<br>www.yandex.ru | | | |

**5 нче сыйныф укучыларының әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр:**

– әдәби әсәрләрне сүзләрен  дөрес әйтеп йөгерек уку;

– авторның әйтергә теләгән фикерен аңлау, үз мөнәсәбәтен белдерү, өлешләргә бүлә һәм планын төзи белү;

– әдәби – теоретик төшенчәләрне рус әдәбият белеме белән тәңгәлләштерү;

– татар әдәбиятының дөнья культурасында тоткан урынын аңлау;

– авторларның тормыш юлы һәм иҗаты турында кыскача күзаллау;

– 8 – 10 татар, рус, чит ил язучысы, шагыйрьләре исемнәрен һәм алар язган әсәрләрне белү;

– 3 – 4 сәнгать әһеленең тормышы, иҗатын турында мәгълүматлы булу;

– Казан һәм Татарстан төбәгендәге мәдәният учаклары (музей, театр, концерт залы, һ. б.), балалар матбугаты турында белү;

– төрле халыкларның фольклор үрнәкләрен  татар халык авыз иҗаты белән чагыштыру;

– төрле халыкларның киң таралган мифларыннан хәбәрдар булу, берничә мисал китерә белү;

– 5 мәкаль, 5 әйтемне русча эквивалентлары белән  истә калдыру;

– мәкаль белән әйтем, миф белән әкият, халык җыры белән автор җыры арасындагы аерманы белү;

– төрле авторларның 2 – 3 шигырен яттан сөйли белү;

– сүзлекләр, энциклопедияләр, Интернет-ресурслардан файдаланып, үзенә кирәкле материалны табу;

– төрле темаларга проект эше яклау;

– әдәби әсәргә тормыш белән бәйләп, үз гамәлләренә бәя бирү

**Кулланылган әдәбият:**

1. «Татар әдәбияты», Рус телендә төп белем бирү оешмалары өчен дәреслек. 7 нче с-ф. 2 кисәктә; төзүче–авторлары Ә.Р.Мотыйгуллина,Р.Г.Ханнанов, Г.Г.Мулласалихова. – Казан: «Мәгариф-Вакыт», 2014 ел.

2. Татар халык әкиятләре: Тылсымлы әкиятләр / Төз. Л.Җамалетдинов. – Казан, 1994.

3. Арсланов М.Г. Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар / М.Г.Арсланов. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 бит: фот.б-н.

4. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

5. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда / төз. Р.Н.Даутов, Р.Н.Рахмани. – Казан: Татар.кит.н.шр., 2009. – Т.I. – 751 б.; Т.II. – 735 б.

6. Әминев А.Г., Әдһәмова Г.М. Урта мәктәптә әдәбият укыту методикасы / А.Г.Әминев. − Казан: Татар. кит. нәшр., 1977.

7. Әминев А.Г., Сайкин Ш.Р. V – VII классларда әдәбият укыту методикасы /Абдулла Әминев, Шәриф Сайкин. − Казан: Татар. кит. нәшр., 1965

8. Бөек Ватан сугышы чоры поэзиясе: Шигырьләр һәм поэмалар. [Төз. һәм кереш сүз авт.Р.Х.Хәйбрахманов]. – Казан: Татарстан Республикасы “Хәтер” нәшр. (ТаРИХ), 2005. – 416 б.

9. Галимуллин Ф.Г. Укучыларны сәнгатьле укырга өйрәтү / Фоат Галимуллин. − Казан: 1988.

## 5 нче сыйныф өчен календарь-тематик план

| № | Дәрес темасы | Дәрес саны | Төп эчтәлек | Дата | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | план | факт |
| 1 | Акыллы сүзгә ни җитә! | 1 | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| 2 | Белмәгән-гә — әкият, белгәнгә — чын. | 1 | Халык авыз иҗатына гомуми күзаллау булдыру, әкият турында белем бирү. | | |
| 3 | Яхшылыкка каршы яхшылык. | 1 | «Ак бүре» әкияте белән танышу. Әкиятне уку. | | |
| 4 | Булма син төлке, булырсың көлке. | 1 | «Абзар ясау-чы Төлке» татар халык әкиятен өйрәнү. | | |
| 5 | Ана дигән хәзинә. | 1 | «Өч кыз» татар халык әкиятен өйрәнү, эчтәлеген үзләштерү. | | |
| 6 | Борын-борын заманда... (Кабатлау дәресе) | 1 | Халык әкиятләрен гомумиләш-тереп кабатлау, аларның төрләргә бүленешен<br>искә төшерү. | | |
| 7 | Яшәгән, ди, булган, ди... | 1 | К.Насыйри-ның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Патша белән карт» әсәрен өйрәнү; «автор әкияте», «әдәби герой» төшенчәләрен аңлату. | | |
| 8 | Юк дип әйтмә, бардыр ул... | 1 | Г.Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Су анасы» әкиятен өйрәнү; «шигъри әсәр», «әкият-поэма» төшенчәләрен аңлату. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9 | Б.Әлменов. «Су анасы» картинасы. | 1 | Рәссам Б.Әлменов-ның тормыш юлы һәм иҗаты турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | | |
| 10 | Әкиятче бездә кунакта. | 1 | Т.Миңнул-линның тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Гафият турында әкият» әсәрен өйрәнү. | | |
| 11 | Әкияттә кунакта. | 1 | «Әкият» курчак театры белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | | |
| 12 | Әкият тә түгел, чын да түгел... | 1 | А.Тимергалин-ның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу, «Сәер планетада» әсәрен уку, эчтәлекне үзләштерү; укучыларда космос, галәм, космик корабльләр белән кызыксынуга омтылыш уяту. | | |
| 13 | Кабатлау дәресе.<br>Хыял дөньясында. | 1 | Әкият һәм фантастика темаларын гомумиләштереп кабатлау, әкият белән фантастиканы аера белү күнекмәләре булдыру. | | |
| 14 | Дәрес-проект. | 1 | Укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү. Әкият һәм фантастика темаларын гомумиләштереп кабатлау, әкият белән фантастиканы аера белү күнекмәләре булдыру. | | |
| 15 | Белем — бәхет ачкычы. | 1 | «Белемгә омтылу» белешмәсен уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, белем алу, укымышлы булу турында фикер алышу, белемгә омтылыш тәрбияләү. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Белем-укудан башлана. | 1 | «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турында уку; татар халкы-ның белемле булуы турында сөйләшү, белем алу, укымышлылык турында фикер алышу, белемгә омтылыш тәрбияләү. | | |
| 17 | Укытучылар мәктәбе. | 1 | Казанның Татар укытучылар мәктәбе турында уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, белем алу, укымышлы булу турында фикер алышу, белемгә омтылыш тәрбияләү. | | |
| 18 | Казан университеты. | 1 | Казан университеты турында уку; татар халкының белемле булуы турында сөйләшү, белем алу, укымышлылык турында фикер алышу, белемгә омтылыш тәрбияләү. | | |
| 19 | Галим кеше хөрмәткә лаек! | 1 | Г.Исхакыйның «Мөгаллим» әсәрен уку, эчтәлекне үзләштерү; укучыларда белемгә омтылыш уяту, укытучы хезмәтенә ихтирам тәрбияләү. | | |
| 20 | Кил, өйрән… | 1 | Дәрдемәнднең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Кил, өйрән…» шигырен өйрәнү. | | |
| 21 | Укысаң – белерсең... | 1 | Мәгърифәтчелек чоры әдәбиятын кабатлау. | | |
| 22 | Г.Тукайның | 1 | «Исемдә калганнар» авто-биографик әсәре аша укучыларны аның балачагы белән таныштыру; әти-әниләргә карата ихтирам | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | «Исендә калганнар” | | тәрбияләү. | | |
| 23 | Бөек Тукай һәм Бәләкәй Апуш. | 1 | Рәссам<br><br>Х.Казаковның тормыш юлы һәм иҗаты турында дәреслектәге белешмә | | |
| 24 | Музейларда — хәтер. | 1 | Габдулла Тукайның Кырлайдагы музее белән дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | | |
| 25 | Кабатлау дәресе.<br><br>Ямьле балачак. | 1 | Укыганнарны гомумиләштереп кабатлау, белем-нәрне тикше-<br><br>рү. | | |
| 26 | «Салават күпере» журналы. | 1 | «Салават күпере» журналы турында дәреслектәге белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | | |
| 27 | Проект-дәрес «Салават күпере — дуслык күпере». | 1 | Укучылар «Салават күпере» журналы белән танышып, аның турында сөйләргә өйрәнәләр. Үз эшеңне тәкъдим итү күнекмәлә-рен булдыру. | | |
| 28 | Гомере аның моңлы бер җыр иде.. | 1 | Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты буенча белемнәрен ныгыту, «Соңгы җыр» шигырен өйрәнү, сугышчыларның батырлыгына ихтирам, фашизм-га карата тарих аша нәфрәт хисе тәрбияләү. | | |
| 29 | Кыр казы | 1 | Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | үзләштерү, Фатих Кәримнең «Кыр казы» шигырен өйрәнү. | | |
| 30 | Кабатлау дәресе.<br><br>Сугыш кайтавазы. | 1 | Бу бүлектә өйрәнелгән материалны гомумиләш-тереп кабатлау, белемнәрне тикшерү. | | |
| 31 | Дәрес-проект<br><br>«Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый...» | 1 | Сугыш елларының әдәбиятта сурәтләнүен аңлау, аны бүгенге күзлектән тасвирлау. | | |
| 32 | «Бәхет кайда була?» | 1 | Нәби Дәүлинең тормыш юлы һәм иҗаты турында белемнәрне үзләштерү, «Бәхет кайда була?» шигырен өйрәнү. | | |
| 33 | Кабатлау дәресе. Туган илем - иркә гөлем. | 1 | Өйрәнелгән материалны гомумиләш-тереп кабатлау, белемнәрне тикшерү. | | |
| 34 | Дәрес-проект«Гүзәл табигатьле туган җирем». | 1 | Әдәбият белән сәнгатьне бәйләп күзаллау. Картина аша әйтергә теләгән фикерләрне сүз белән әйтергә өйрәтү. | | |
| 35 | Йомгаклау | 1 | Гомумиләштереп кабатлау | | |